КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.05.2023 Казан шәһәре № 184-П

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районында урнашкан «Дальненовское поселение I»
ачыкланган мәдәни мирас объектын ачыкланган
мәдәни (археологик) мирас исемлегенә кертү,
территориясенең чикләрен һәм аннан файдалану
режимын раслау турында

2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендән б о е р а м:

1. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Дальнеивановское поселение I» археологик мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Дальнеивановское поселение I» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләрен расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

3. Әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Дальнеивановское поселение I» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектының ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга.

4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләр кертүне күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

5. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Комитет рәисе урынбасары М.М. Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан
Республикасы мәдәни
мирас объектларын
саклау комитетының
2023 елның
18 маендагы 184-П
боерыгына 3 кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Дальнеивановское поселение I» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясен файдалану режимы

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү шартларында урманнардан файдалану һәм башка эшләр буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башкару, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен тәэмин итү шартларында археологик кыр эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.